шулай ук әлеге бүлмәдән социаль наем шартларында файдалану хокукына ия затларга карата түбәндәге документларны тапшыра:

1) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ (Бердәм, Республика порталлары аша мөрәҗәгать иткәндә таләп ителми);

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;

3) гариза:

кәгазь документ формасында (административ регламентка 4 нче кушымта);

Бердәм, Республика порталлары аша мөрәҗәгать иткәндә, административ регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон

формасына тиешле мәгълүматларны кертү юлы белән тутырыла);

4) гаиләнең һәр әгъзасының шәхесен раслаучы документлар күчермәләре;

5) Россия Федерациясенең барлык теркәлгән, шулай ук теркәү исәбеннән төшерелгән, ләкин торак урыннан файдалану хокукын югалтмаган гражданнар турында мәгълүматларны үз өченә алган, приватизацияләнә торган торак урында теркәлгән затлар турында мәгүлүматлар;

6) күчемсез милек объектының техник паспорты;

7) 1991 елның 11 июленнән башлап 2000 елның 1 гыйнварына кадәр элеккеге яшәү урыны буенча приватизацияләүдә катнашуга файдаланылмаган хокукын раслаучы вәкаләтле орган документы;

8) яшәү урыны буенча гариза бирүче белән теркәлгән бер яки берничә затның приватизацияләүдә катнашудан баш тартуы турында нотариаль расланган ризалыгы;

9) анда элек теркәлгән, ләкин әлеге торак урыннан файдалану хокукын югалтмаган балигъ булмаган затның торак урынны приватизацияләүдә катнашудан баш тартуы турында опека һәм попечительлек өлкәсендә вәкаләтле органның рөхсәте;

10) гражданны хокукка сәләтсез/хокукка сәләте чикле дип тану турында үз көченә кергән суд карары (карарны кабул иткән суд тарафыннан расланган күчермә);

11) торак урынны приватизацияләү тәртибендә хокукка сәләтсез/хокукка сәләте чикле граждан милкенә, шулай ук ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларга күзәтчелек астына куелган балалар милкенә тапшыруга опека һәм попечительлек өлкәсендә вәкаләтле орган ризалыгы;

12) торак урынга торак яки мөлкәт хокуклары булу яки мәхрүм итү (булмау) турында законлы көченә кергән суд карары – мондый затларга карата үз көченә кергән суд карары (карарны кабул иткән суд тарафыннан раслаган күчермә) булганда;

13) контракт буенча хәрби хезмәт үтүче (үткән) һәм аларның гаилә әгъзалары, шул исәптән запаска азат ителгән очракта – хезмәт үтү чорын, гаилә составын һәм чорлар буенча хәрби часть каршында теркәлү чагылышын күрсәтеп шәхси делодан өземтә (белешмә); хезмәт шартнамәсе (контракт) чорына хәрби часть каршындагы хезмәт урыныннан бирелә торган торак файдалануга бирелгән (бирелгән булган) гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары);

14) иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтәгән очракта:

- законлы көченә кергән суд хөкеме, шулай ук иректән мәхрүм итүгә яки мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән гражданнар тарафыннан җәза үтәүне раслаучы документ (Россия Федерациясе Конституция судының 1995 елның 23 июнендәге 8-П номерлы карары нигезендә), үз көченә кергән суд хөкеме (карарны кабул иткән суд тарафыннан расланган күчермә);

- приватизацияләүдә катнашучы гражданны азат итү турында белешмә.

2.5.2. Гариза һәм теркәлгән документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:

## 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр юк.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектән файдаланып алынган документларның яки мәгълүматларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларга яки мәгълүматларга каршы килүе;

2) административ регламент нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче булып тормаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе (күрсәтелгән нигез муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар кабул итү процедурасында ачыкланган очракта);

3) гариза бирүченең, гариза бирүченең гаилә әгъзаларының берсенең, приватизацияләнә торган торак урында теркәлгән затларның, әлеге бүлмәдән социаль наем шартларында файдалану хокукына ия һәм приватизацияләү хокукыннан файдаланмаган затларның торак урынны приватизацияләүгә ризалыгы булмау;

4) гариза бирүченең, гариза бирүченең гаилә әгъзаларының берсенең, приватизацияләнә торган торак урында теркәлгән башка затның, әлеге бүлмәдән социаль наем шартларында файдалану хокукына ия 14 яшькә җиткән затның һәм/яки аның законлы вәкиленең яки билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле затның приватизацияләүне рәсмиләштерү ниятләре булмау турында мөрәҗәгате;

5) гариза бирүче белән яшәү урыны буенча теркәлгән бер яки берничә затның торак урынны приватизацияләүдән баш тартуы;

6) приватизацияләү хокукыннан элек файдаланылган булу;

7) авария хәлендәге торак урынны, махсуслаштырылган торак фондының торак урынын приватизацияләү турында запрос белән мөрәҗәгать итү;

8) башка муниципаль районнардан (шәһәр округларыннан) приватизацияләүдә катнашуны (катнашмауны) раслаучы мәгълүматлар булмау/тапшырылмау;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органында гариза бирүче тарафыннан приватизацияләнә торган торак урынга милек хокукы булмау;

10) муниципаль хезмәт күрсәтү чорында паспорт һәм/яки башка персональ мәгълүматлар үзгәрү;

11) торак урынга арест салыну;

12) муниципаль хезмәт күрсәтү чорында приватизацияләнә торган торак урынында гариза бирүче белән яшәүче затлар составы үзгәрү;

13) гариза бирүченең гаилә составында приватизацияләнә торган торак урында теркәлгән затлар, әлеге бүлмәдән социаль наем шартларында файдалану хокукына ия затлар (тиешле затлардан торак урынны приватизацияләү өчен ризалык бирелмәгән яки тиешле затларның торак урынны приватизацияләү хокукы булмауны раслаучы мәгълүматлар тапшырылмаган очракта): - стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларыннан киткән гражданнар; - вакытлыча булмаган гражданнар (хезмәт итү өчен Кораллы Көчләр сафларына, уку/эшләү чорында вакытлыча яшәү өчен бирелгән торак урыннарына китүчеләр); - иректән мәхрүм ителгән урыннарга киткән яки мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән гражданнар (Россия Федерациясе Конституция судының 1995 елның 23 июнендәге 8-П номерлы карары нигезендә); - суд карарлары нигезендә теркәлү исәбеннән төшерелгән, ләкин торак урыннан файдалану хокукын саклаган гражданнар; төгәл адресын күрсәтмичә, теркәлү исәбеннән төшерелгән гражданнар булу. Югарыда санап үтелгән категорияләрдәге гражданнарның торак урынын приватизацияләү теләген белдерә торган документлар (баш тартуга ризалык

# ШАРТНАМӘНЕҢ ШАРТЛАРЫ

3. «Граждан» приватизацияләү хокукыннан файдаланмаган.

4. «Граждан» Бердәм дәүләт күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән килешүләр реестрында хокукны дәүләт теркәвенә алган вакыттан башлап торак урынга милек хокукын ала.

5. «Граждан» муниципаль торак фондындагы торак урынны приватизацияләү тәртибендә бер генә тапкыр милеккә түләүсез алырга хокуклы. Приватизацияләү тәртибендә били торган торак урын милекчесе булып торган балигъ булмаганнар, балигъ булганнан соң муниципаль торак фонды йортларындагы башка торак урынны бер тапкыр түләүсез приватизацияләү хокукын саклыйлар.

6. «Граждан», торак урын милекчесе буларак, аның Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән билгеләнеше һәм аннан файдалану чикләре нигезендә, милек хокукындагы торак урынга ия булу, файдалану һәм аның белән эш итү хокукларын гамәлгә ашыра.

7. «Граждан», милекче буларак, күпфатирлы йорттагы торак урыннан Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән максатларда һәм чикләрдә файдалана.

8. «Граждан» шулай ук, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәттән файдаланучы сыйфатында файдалана.

9. Күпфатирлы йорттагы бүлмәне милеккә алган вакытта, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә уртак милек хокукындагы өлеш «Граждан»га күчә. Күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә уртак милек хокукындагы өлеш «Милекче»нең әлеге шартнамәнең 1 пунктында күрсәтелгән бүлмәсенең гомуми мәйданы күләменә пропорциональ.

10. Күпфатирлы йорттагы торак» «Милекче»се хокуклы түгел:

1) күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә милек хокукындагы үз өлешен чынлыкта бүлеп бирүне гамәлгә ашырырга;

2) күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә уртак милек хокукындагы үз өлешен читләштерергә, шулай ук бу өлешне күрсәтелгән бүлмәгә милек хокукыннан аерым бирүгә китерә торган башка гамәлләр кылырга.

Бу йорттагы торак «Милекче»сенең күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә гомуми милек хокукындагы өлеше торак урынга (бүлмәгә, бүлмәләргә) милек хокукынан чыгып билгеләнә.

11. «Милекче» һәм аның гаилә әгъзалары арасында килешү буенча башкача билгеләнмәсә, «Милекче»нең гаилә әгъзалары торак урыннан аның белән бертигез файдалану хокукына ия.

12. «Милекче» гаиләсенең хокукка сәләтле әгъзалары, әгәр «Милекче» һәм аның гаилә әгъзалары арасындагы килешү буенча башкача билгеләнмәгән булса, торак урыннан файдаланудан барлыкка килә торган йөкләмәләр буенча «Милекче» белән уртак җаваплылык тоталар.

13. Әлеге торак «Милекче»се белән килешү нигезендә торак урыннан файдаланучы граждан, мондый килешү шартлары нигезендә хокуклы, бурычлы һәм җаваплы була.

14. Әлеге шартнамә буенча бәхәсләр яклар килешүе буенча хәл ителә, мондый килешүгә ирешә алмаганда – суд тәртибендә.

15. Әлеге шартнамә ике нөсхәдә төзелде. Шартнамәнең бер нөсхәсе «Граждан»ның кулына яки ышаныч язуы буенча аның вәкиленә бирелә. Шартнамәнең икенче нөсхәсе Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетында кала.

